Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
карары

16 март 2020 ел № 352

Экологик экспертиза узарга тиешле
билгеләнгән хуҗалык эшчәнлеге
турында иҗтимагый тыңлау рәвешендә
иҗтимагый фикер алышуны билгеләү
һәм уздыру турында

«Экологик экспертиза турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, «Россия Федерациясендә әйләнә-тирә мохитне саклау буенча Россия Федерациясе Дәүләт комитетының 2000 елның 16 маендагы 372 номерлы «Россия Федерациясендә ниятләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек йогынтысын бәяләү турындагы нигезләмәне раслау турында» боерыгына таянып, җәмәгать фикер алышуын үткәрү кирәклеге турында В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең мөрәҗәгатен карап,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. «Бораулауның өстәмә продуктын - планировкалар өчен грунтны җитештерүнең технологик регламенты» техник документация проекты буенча В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең хуҗалык эшчәнлеген билгеләү турындагы материалларны карау буенча иҗтимагый тыңлау рәвешендә җәмәгатьчелек фикер алышуын билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Дату и время проведения – 2020 елның 23 апрелендә 11: 00 сәгатьтә;

2.2. Үткәрү вакыты 1 көн;

2.3. Үткәрү урыны - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, шәһәр җирлеге - Әлмәт шәһәре, Әлмәт шәһәре, Ленин ур., 39 й. каб.325;

2.4. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре шәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре, Әминова ур., 9А йорт, 1 каб. адресы буенча урнашкан Фикер алыша торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, «Экология һәм табигатьтән файдалану департаменты» муниципаль бюджет учреждениесенә гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар тапшырырга.

2.5. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен заявкалар бирү срогы - 2020 елның 23 апреленә кадәр.

3. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Экология һәм табигатьтән файдалану департаменты» муниципаль бюджет учреждениесенә (Исхаков А.Р.) беркетмә үткәрү, әзерләү һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бирүне оештырырга.

4. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре шәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре, Әминова ур., 9А йорт, 1 каб., Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Бөгелмә шәһәре, Муса Җәлил ур., 64, 409 бүл., www.tatneft.ru компаниясенең рәсми интернет-сайтында (Экология» бүлегендә) адреслар буенча иҗтимагый фикер алышулар үткәрү

турында мәгълүмат басылып чыккан көннән алып 30 көн эчендә дәүләт экология экспертизасы объекты документациясе белән танышырга мөмкин.

5. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) 2020 елның 19 мартында урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов